| КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 19 май г.Казань № 407

Яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга һәм яңа коронавирус йогышлы авыруы йоктыру рискы төркемнәреннән булган затларга социаль хезмәтләр күрсәтүче стационар социаль хезмәт күрсәтү оешмалары, стационар социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында оештырылмаган стационар бүлекчәләр хезмәткәрләренә махсус хезмәт шартлары һәм өстәмә йөкләнеш өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләрне гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанслар белән тәэмин итү кагыйдәләрен һәм Яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга һәм яңа коронавирус йогышлы авыруы йоктыру рискы төркемнәреннән булган затларга социаль хезмәтләр күрсәтүче стационар социаль хезмәт күрсәтү оешмалары, стационар социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында оештырылмаган стационар бүлекчәләр хезмәткәрләренә махсус хезмәт шартлары һәм өстәмә йөкләнеш өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләрне бирү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2020 елда яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга һәм яңа коронавирус йогышлы авыруы йоктыру рискы төркемнәреннән булган затларга социаль хезмәтләр күрсәтүче стационар социаль

хезмәт күрсәтү оешмалары, стационар социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында оештырылмаган стационар бүлекчәләр хезмәткәрләренә махсус хезмәт шартлары һәм өстәмә йөкләнеш өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләрне гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган Россия Федерациясе субъектларының чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып Россия Федерациясе Хөкүмәтенең резерв фонды бюджет ассигнованиеләре торган Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан башка бюджетара трансфертлар бирү кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 15 маендагы 681 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

Яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга һәм яңа коронавирус йогышлы авыруы йоктыру рискы төркемнәреннән булган затларга социаль хезмәтләр күрсәтүче стационар социаль хезмәт күрсәтү оешмалары, стационар социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында оештырылмаган стационар бүлекчәләр хезмәткәрләренә махсус хезмәт шартлары һәм өстәмә йөкләнеш өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләрне гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанслар белән тәэмин итү кагыйдәләрен;

Яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга һәм яңа коронавирус йогышлы авыруы йоктыру рискы төркемнәреннән булган затларга социаль хезмәтләр күрсәтүче стационар социаль хезмәт күрсәтү оешмалары, стационар социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында оештырылмаган стационар бүлекчәләр хезмәткәрләренә махсус хезмәт шартлары һәм өстәмә йөкләнеш өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләрне бирү тәртибен.

2. Бу карарның гамәле 2020 елның 15 апреленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры　　　　　　　　　　　　　　　　А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 19 май, 407 нче
карары белән расланды

Яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга һәм яңа коронавирус йогышлы авыруы йоктыру рискы төркемнәреннән булган затларга социаль хезмәтләр күрсәтүче стационар социаль хезмәт күрсәтү оешмалары, стационар социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында оештырылмаган стационар бүлекчәләр хезмәткәрләренә махсус хезмәт шартлары һәм өстәмә йөкләнеш өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләрне гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанслар белән тәэмин итү кагыйдәләре

1. Бу Кагыйдәләр яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга һәм яңа коронавирус йогышлы авыруы йоктыру рискы төркемнәреннән булган затларга социаль хезмәтләр күрсәтүче Татарстан Республикасының стационар социаль хезмәт күрсәтү оешмалары, Татарстан Республикасының стационар социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында оештырылмаган стационар бүлекчәләр хезмәткәрләренә махсус хезмәт шартлары һәм өстәмә йөкләнеш өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләрне гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанслар белән тәэмин итү механизмын билгели.

2. Яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга һәм яңа коронавирус йогышлы авыруы йоктыру рискы төркемнәреннән булган затларга социаль хезмәтләр күрсәтүче Татарстан Республикасының стационар социаль хезмәт күрсәтү оешмалары, Татарстан Республикасының стационар социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында оештырылмаган стационар бүлекчәләр хезмәткәрләренә махсус хезмәт шартлары һәм өстәмә йөкләнеш өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләрне гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанслар белән тәэмин итү яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга һәм яңа коронавирус йогышлы авыруы йоктыру рискы төркемнәреннән булган затларга социаль хезмәтләр күрсәтүче Татарстан Республикасының стационар социаль хезмәт күрсәтү оешмалары, Татарстан Республикасының стационар социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында оештырылмаган стационар бүлекчәләр хезмәткәрләренә махсус хезмәт шартлары һәм өстәмә йөкләнеш өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләрне гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Татарстан Республикасы бюджетына федераль бюджеттан бирелә торган башка бюджетара трансферты акчасы (алга таба шул ук эзлеклелектә – стационар социаль хезмәт күрсәтү оешмалары, стационар бүлекләр, стимуллаштыру характерындагы түләүләр, башка бюджетара трансферт) исәбеннән гамәлгә ашырыла.

Башка бюджетара трансферт акчасы, стационар социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының, стационар бүлекчәләрнең махсус эш режимын күздә тота торган чикләү чаралары (социаль хезмәтләрдән файдаланучыларның, шулай ук, эш сменасының кимендә 14 календарь көн дәвамлылыгыннан чыгып, социаль хезмәт күрсәтү оешмалары хезмәткәрләренең стационар оешмада, стационар бүлекчәдә яшәвен вакытлыча изоляцияләү (обсервацияләү)) кертелгән очракта, 2020 елның 15 апреленнән 15 июленә кадәрге чор өчен стационар социаль хезмәт күрсәтү оешмалары, стационар бүлекләре (алга таба – социаль хезмәт күрсәтү оешмалары) хезмәткәрләренә стимуллаштыру характерындагы түләүләрне гамәлгә ашыруга тотыла.

3. Бу Кагыйдәләрнең 2 нче пунктында күрсәтелгән чараларны тормышка ашыруга каралган Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүче булып Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тора.

4. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы башка бюджетара трансферт акчасын бу Кагыйдәләрнең 2 нче пунктында күрсәтелгән чараларны тормышка ашыруга җибәрә.

5. Башка бюджетара трансферт акчасын (алга таба – акча) тоту Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсендә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына ачылган шәхси исәп аша гамәлгә ашырыла.

6. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, финанслауның иң чик күләмнәре Россия Федерациясе Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан җиткерелгәннән соң, финанслауның иң чик күләмнәрен Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре күләмнәре һәм расланган бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә җиткерә.

7. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы бу Кагыйдәләрнең 2 нче пунктында күрсәтелгән чараларны тормышка ашыру максатларында:

бюджет һәм автоном учреждениеләр булган социаль хезмәт күрсәтү оешмалары белән Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының «Татарстан Республикасы дәүләт бюджет яки автоном учреждениесенә Россия Федерациясе Бюджет кодексының 781 статьясындагы 1 пунктының икенче абзацы нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү турындагы килешүнең бертип формасын раслау хакында» 2016 елның 22 декабрендәге 17-148 номерлы боерыгы белән расланган форма буенча Россия Федерациясе Бюджет кодексының 781 статьясындагы 1 пунктының икенче абзацы нигезендә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасының дәүләт бюджет һәм автоном учреждениеләренә дәүләт йөкләмәсен үтәүне финанслар белән тәэмин итүгә бәйле булмаган башка максатларга субсидияләр бирү шартларын һәм күләмен билгеләү тәртибен раслау турында» 2016 ел, 30 декабрь, 1052 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы бюджетыннан

Татарстан Республикасының дәүләт бюджет һәм автоном учреждениеләренә дәүләт йөкләмәсен үтәүне финанслар белән тәэмин итүгә бәйле булмаган башка максатларга субсидияләр бирү шартларын һәм күләмен билгеләүтәртибе нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү турында килешүләр төзи;

агымдагы финанс елына финанслауның иң чик күләмнәрен казна оешмалары булган социаль хезмәт күрсәтү оешмаларына социаль хезмәт күрсәтү оешмалары заявкалары нигезендә Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан билгеләнгән агымдагы финанс елына бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә җиткерә;

субсидия акчасын Татарстан Республикасы бюджетыннан бюджет һәм автоном социаль хезмәт күрсәтү оешмаларына социаль хезмәт күрсәтү оешмалары заявкалары нигезендә күчерә.

8. Социаль хезмәт күрсәтү оешмалары Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты арасында башка бюджетара трансферт бирү турындагы килешүдә билгеләнгән тәртиптә һәм форма буенча акчаны файдалану турында хисаплар тапшыра.

9. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы түбәндәге очракларда бирелгән акчаны социаль хезмәт күрсәтү оешмалары тарафыннан кире кайтаруны тәэмин итә:

акчага ихтыяҗ булмаганда (кимегәндә);

социаль хезмәт күрсәтү оешмалары дөрес булмаган хисаплылык тапшырганда;

социаль хезмәт күрсәтү оешмалары акчаны максатчан файдаланмаганда.

10. Бу Кагыйдәләрнең 9 нчы пунктында күрсәтелгән очракларда, социаль хезмәт күрсәтү оешмаларына бирелгән акча Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының тиешле таләбе алынган көннән 15 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

Социаль хезмәт күрсәтү оешмалары тарафыннан акчаны кире кайтару вакыты бозылганда Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы бу пунктның беренче абзацында билгеләнгән вакыт тәмамланган көннән 30 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджетына акчаны законнар белән билгеләнгән тәртиптә түләтү буенча чаралар күрә.

11. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы стимуллаштыру характерынданы түләүләрне гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанслар белән тәэмин итүгә кергән башка бюджетара трансферт акчасын максатчан файдалануны тикшерүдә тотуны тәэмин итә.

12. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы финанслар белән тәэмин итү максатларында башка бюджетара трансферт бирелә торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары турында «Электрон бюджет» иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең дәүләт интеграцияләнгән мәгълүмат системасында Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты арасында

башка бюджетара трансферт бирү турындагы килешү белән билгеләнгән форма буенча һәм вакытларда хисап урнаштыра.

13. Башка бюджетара трансферт акчасын максатчан файдаланмау Россия Федерациясе бюджет законнары нигезендә җаваплылыкка тарта.

14. Агымдагы финанс елының 1 гыйнварына башка бюджетара трансферт акчасының файдаланылмый калган өлеше федераль бюджетка Россия Федерациясе бюджет законнары белән билгеләнгән таләпләр нигезендә кире кайтарылырга тиеш.

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 19 май, 407 нче
карары белән расланды

## Яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга һәм яңа коронавирус йогышлы авыруы йоктыру рискы төркемнәреннән булган затларга социаль хезмәтләр күрсәтүче стационар социаль хезмәт күрсәтү оешмалары, стационар социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында оештырылмаган стационар бүлекчәләр хезмәткәрләренә махсус хезмәт шартлары һәм өстәмә йөкләнеш өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләрне бирү тәртибе

1. Бу Тәртип яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга һәм яңа коронавирус йогышлы авыруы йоктыру рискы төркемнәреннән булган затларга социаль хезмәтләр күрсәтүче Татарстан Республикасының стационар социаль хезмәт күрсәтү оешмалары, Татарстан Республикасының стационар социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында оештырылмаган стационар бүлекчәләре хезмәткәрләренә махсус хезмәт шартлары һәм өстәмә йөкләнеш өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләрне (алга таба шул ук эзлеклелектә – социаль хезмәт күрсәтү оешмасы, стационар бүлек, стимуллаштыру характерындагы түләүләр) бирү максатын, тәртибен һәм шартларын билгели.

2. Стимуллаштыру характерындагы түләүләр, стационар социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының, стационар бүлекчәләрнең махсус эш режимын күздә тота торган чикләү чаралары (социаль хезмәтләрдән файдаланучыларның, шулай ук, эш сменасының кимендә 14 календарь көн дәвамлылыгыннан чыгып, социаль хезмәт күрсәтү оешмалары хезмәткәрләренең стационар оешмада, стационар бүлекчәдә яшәвен вакытлыча изоляцияләү (обсервацияләү) кертелгән очракта, 2020 елның 15 апреленнән 15 июленә кадәрге чор өчен стационар социаль хезмәт күрсәтү оешмалары, стационар бүлекләр (алга таба – социаль хезмәт күрсәтү оешмалары) хезмәткәрләренә билгеләнә.

3. Стимуллаштыру характерындагы түләүләр түбәндәге күләмнәрдә (бер эш сменасы дәвамында эшләгән өчен) билгеләнә:

а) табибларга: стационар социаль хезмәт күрсәтү оешмасында, стационар бүлектә яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланмаган очракта – 40 мең сум, ачыкланган очракта – 60 мең сум;

б) урта медицина персоналына, шул исәптән фельдшерларга, медицина дезинфекторларына, лаборантларга, массаж буенча шәфкать туташларына, процедура шәфкать туташларына, физиотерапия буенча шәфкать туташларына, өлкән шәфкать туташларына, дәвалау физкультурасы буенча инструкторларга, дәвалау физкультурасы буенча инструктор-методистларга: стационар социаль хезмәт күрсәтү оешмасында, стационар бүлектә яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланмаган очракта – 25 мең сум, ачыкланган очракта – 35 мең сум;

в) социаль хезмәткәрләргә, социаль эш буенча белгечләргә, гаилә белән эшләү буенча белгечләргә, социаль өлкәдә тернәкләндерү эше буенча белгечләргә, социаль өлкәдә психологларга, педагогик хезмәткәрләргә, шул исәптән тәрбиячеләргә, хезмәт буенча инструкторларга, логопедларга, музыка буенча җитәкчеләргә, педагог-китапханәчеләргә, педагог-оештыручыларга, педагог-психологларга, социаль педагогларга, педагог-дефектологларга, укытучы-логопедларга, административ-идарә персоналына: стационар социаль хезмәт күрсәтү оешмасында, стационар бүлектә яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланмаган очракта – 25 мең сум, ачыкланган очракта – 35 мең сум;

г) кече медицина персоналына, шул исәптән психоневрологик интернатларның, акыл үсеше артта калган балалар өчен балалар интернат йортларының шәфкать туташларына, санитарларга, шулай ук сиделкаларга (карау буенча ярдәмчеләргә): стационар социаль хезмәт күрсәтү оешмасында, стационар бүлектә яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланмаган очракта – 15 мең сум, ачыкланган очракта – 20 мең сум;

д) техник персоналга, башка вазыйфаларда эшләүче персоналга: стационар социаль хезмәт күрсәтү оешмасында, стационар бүлектә яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланмаган очракта – 10 мең сум, ачыкланган очракта – 15 мең сум.

4. Стационар социаль хезмәт күрсәтү оешмалары, стационар бүлекләр оештырылган социаль хезмәт күрсәтү оешмалары локаль норматив акт белән түбәндәгеләрне билгели:

а) хезмәткәрләргә аларда эшләү стимуллаштыру характерындагы түләүләрне билгеләү хокукын бирә торган стационар социаль хезмәт күрсәтү оешмасында, стационар бүлекчәдә, эш сменасының дәвамлылыгын кимендә 14 календарь көн итеп билгеләп, сменалы эш режимын күздә тота торган чикләү чараларын;

б) аларда эшләү стимуллаштыру характерындагы түләүләрне билгеләү хокукын бирә торган стационар социаль хезмәт күрсәтү оешмасы, стационар бүлекчә хезмәткәрләренең бу Тәртипнең 3 нче пункты нигезендә вазыйфалар исемлеген;

в) стационар социаль хезмәт күрсәтү оешмасында, стационар бүлектә яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган очракта, бу Тәртипнең 3 нче пункты нигезендә дифференциацияләнгән һәм биләгән вазыйфа нигезендә стимуллаштыру характерындагы түләү күләмен;

г) стимуллаштыру характерындагы түләү билгеләнә торган вакытны.

5. Стационар социаль хезмәт күрсәтү оешмасы, стационар бүлек хезмәткәре сменада эшләгән чорда анда яңа коронавирус йогышлы авыруы булу ачыкланганда аңа стимуллаштыру характерындагы түләүне тулы күләмдә бирү хокукы саклана.

6. Социаль хезмәт күрсәтү оешмалары, стационар бүлекләр оештырылган социаль хезмәт күрсәтү оешмалары стимуллаштыру характерындагы түләүләрне гамәлгә ашыру акчасын максатчан файдалану өчен җавап бирә.